ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә матди һәм социаль гарантияләрне арттыру буенча кичектергесез чаралар күрү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә матди һәм социаль гарантияләрне арттыру буенча кичектергесез чаралар күрү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга җибәрергә.
3. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге мөрәҗәгатен хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 324-VII ДС

Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә матди һәм социаль гарантияләрне арттыру буенча кичектергесез чаралар күрү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате

Хөрмәтле Михаил Владимирович!

Россия Федерациясе эчке эшләр органнары системасыннан кадрларның сизелерлек дәрәҗәдә китүе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын нык борчый.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында 2025 елның дүрт аенда эштән киткән хезмәткәрләр саны узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 28,8 процентка (531 алып 746 кадәр) артты. 2024 елда республикада эчке эшләр органнарыннан 1800 күбрәк хезмәткәр эштән китте. Чагыштыру өчен: 2020 елда бу күрсәткеч 966 тәшкил итте.

411 хезмәткәр (агымдагы елда эштән киткәннәрнең 55,1 проценты) тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына җиткәнче үк эштән китте.

Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр органнарында шәхси составның комплекты 26,3 процентка (2024 елда – 22,7 процентка) тулы түгел. Эшчәнлек юнәлешләре буенча хезмәтләр җәһәтеннән караганда комплектлау мәсьәләсендә иң авыр хәл түбәндәге бүлекләрдә: патруль-пост хезмәте – 39,9 процент, вәкаләтле участок полициясе – 36,2 процент, наркотиклар әйләнешен тикшереп тору – 33,9 процент, җинаятьчеләрне эзләү – 33,2 процент, тикшерү – 31,8 процент, дежур частьлар – 27,1 процент, икътисадый иминлек һәм коррупциягә каршы көрәш – 23,2 процент, сорау алу – 22,3 процент.

Эчке эшләр органнарыннан киткән хезмәткәрләр саны Россия Федерациясендә, тулаем алганда, шулай ук даими арта бара. Массакүләм мәгълүмат чаралары белешмәләре буенча, 2024 елның ахырына Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгында шәхси составның комплектта булмавы 174 мең кешегә җитте, бу штат саныннан 18,9 процент тәшкил итә. Мондый негатив тенденция, үз чиратында, кадрларның алга таба да эштән китүен активлаштыра, чөнки калган хезмәткәрләр комплектның тулы булмавы шартларында өстәмә йөкләнеш белән эшләргә мәҗбүр була.

Эштән киткән хезмәткәрләр белән үткәрелгән әңгәмәләрне анализлау эчке эшләр органнарыннан китүнең түбәндәге сәбәпләрен күрсәтә: күбрәк түләнә торган эшкә урнашу тәкъдимнәре булганда хезмәт хакыннан, социаль яклау дәрәҗәсеннән канәгать булмау (җавап биргәннәрнең 87,6 проценты), балаларны яисә каты авыруы булган туганнарны карап тору зарурлыгы, башка торак пунктка күченеп китү, бүтән дәүләт органнарына эшкә урнашу, алга

таба эшкә урнашмыйча пенсиягә чыгу һәм башкалар (җавап биргәннәрнең 12,4 проценты).

2023 елда Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләренең акчалата түләү окладларын индексацияләү буенча күрелгән чаралар Россия Федерациясе субъектларындагы уртача хезмәт хакы дәрәҗәсен узып китү мөмкинлеген бирмәде.

Пенсия алу хокукына ия булган хезмәткәрләрнең алга таба да эчке эшләр органнарында хезмәт итүгә мотивациясе булмавы проблемалы мәсьәлә булып кала, чөнки законнарда пенсияне алу хезмәттән киткәч кенә мөмкин дип каралган.

Моннан тыш, эчке эшләр органнары хезмәткәрләре өчен билгеләнгән берничә ташламаның җитәрлек дәрәҗәдә гамәлгә ашырылмавы җитди проблема булып тора.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында торак урынны сатып алу яисә төзү өчен бер мәртәбә бирелә торган социаль түләү алуга 1821 хезмәткәр чират тора. Ел саен мондый түләү уртача 55 хезмәткәргә (2022 елда – 67, 2023 елда – 50, 2024 елда – 47, 2025 елда – 3) бирелә. Шул рәвешле, түләү бирүне көтүнең уртача вакыты 33 ел тәшкил итә.

Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең торак проблемаларын хәл кылуга торак урыннарны яллау (өстәмә яллау) чыгымнарын компенсацияләүнең гамәлдәге механизмы шулай ук ярдәм итми. 2025 елның маенда Казан шәһәрендә бер бүлмәле фатирны арендалауның уртача айлык бәясе 34 мең сум тәшкил итте, ә хезмәт урыны буенча торак урыны булмаган хезмәткәргә билгеләнә торган акчалата компенсация 2011 елның 30 декабрендәге 1228 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының 2 пункты нигезендә 2025 елда аена 8 707,44 сум тәшкил итә.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, федераль законнарга түбәндәге өлешләрдә үзгәрешләр кертү зарурлыгы бар:

эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең акчалата түләвен арттыру;

пенсия алу хокукына ия булган эчке эшләр органнарының гамәлдәге хезмәткәрләренә эштән киткән очракта билгеләнергә мөмкин булган пенсия күләменнән 50 процент күләмендә өстәмә түләү билгеләү;

эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә хәрби хезмәткәрләрне торак белән тәэмин итүнең тупланма-ипотека системасында кебек үк фатир сатып алу мөмкинлеген бирү;

эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә торакны арендалау өчен түләүне каплау күләмен яшәү регионындагы аренда бәясенең уртача базар дәрәҗәсенә кадәр арттыру.

Моннан тыш, шулай ук эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә Россия Федерациясе субъектының һәм муниципаль берәмлекләрнең бюджет акчаларын җәлеп итеп матди ярдәм күрсәтүне законнар дәрәҗәсендә беркетү мөмкинлеген карауны тәкъдим итәбез.

Тәкъдим ителә торган үзгәрешләр шәхси составның кадрлар үзәген саклап калу һәм гражданнар өчен эчке эшләр органнарында хезмәт итүнең җәлеп итүчәнлеген арттыру мөмкинлеген бирәчәк.